ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 14 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяның 1 өлешенә «игълан ителүенә бәйле рәвештә» сүзләреннән соң «, шулай ук граждан хәле акты язмасына ир белән хатынның берәрсе җенесен үзгәртүе турында үзгәреш кертүгә бәйле рәвештә» сүзләрен өстәргә;

2) 79 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Мондый ярдәмнән баш тарткан һәм алимент түләү турында ир белән хатын арасында килешү булмаган очракта, матди мөмкинлеге булган ирдән йә хатыннан суд тәртибендә алимент түләүне таләп итү хокукына түбәндәгеләр ия:

1) хезмәткә сәләтсез ярдәмгә мохтаҗ ир йә хатын;

2) йөклелек чорында ир хатыны;

3) уртак бала туган көннән алып өч ел дәвамында фактта аны карап торучы ир йә хатын;

4) уртак инвалид баланы аңа унсигез яше тулганчы карап торучы яисә балачактан I төркем инвалид уртак баланы фактта карап торучы ярдәмгә мохтаҗ ир йә хатын.»;

3) 80 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Матди мөмкинлеге булган элеккеге ирдән йә хатыннан суд тәртибендә алимент түләүне таләп итү хокукына түбәндәгеләр ия:

1) никахта торганда барлыкка килгән йөклелек чорында элеккеге ир хатыны;

2) уртак бала туган көннән алып өч ел дәвамында фактта аны карап торучы элеккеге ир йә хатын;

3) уртак инвалид баланы аңа унсигез яше тулганчы фактта карап торучы яисә балачактан I төркем инвалид уртак баланы фактта карап торучы ярдәмгә мохтаҗ элеккеге ир йә хатын;

4) никах өзелгәнче яисә никах өзелү вакытыннан бер ел дәвамында хезмәткә сәләтсез булып калган ярдәмгә мохтаҗ элеккеге ир йә хатын;

5) никахлары өзелгәннән соң биш елдан соңрак булмаган вакыт эчендә пенсия яшенә җиткән ярдәмгә мохтаҗ элеккеге ир йә хатын, әгәр ир белән хатын озак вакыт никахта торса.»;

4) 116 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

«14) җенесен үзгәрткән затлар.»;

5) 134 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) җенесен үзгәрткән затлар.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 29 сентябрь
№ 92-ТРЗ